**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**(III чакырылыш)**

**егерме сигезенче утырыш**
# КАРАРЫ

14 июнь 2019 ел **№ 175** Теләче авылы

Теләче муниципаль районы Советының «Муниципаль милек исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга файдалануга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль милкен (җир участокларыннан башка) арендага бирү Тәртибен һәм Исемлеккә кертелгән муниципаль милекне формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибен раслау турында»гы 2017 елның 20 апрелендәге 83 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында»гы 2007 елның 24 июлендәге 209 номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 21 августындагы 645 номерлы «Федераль милек биргәндә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү турында»гы карары нигезендә Теләче муниципаль районы Советы **карар бирде,**

1. Теләче муниципаль районы Советының «Муниципаль милек исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектла рының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга файдалануга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль милкен (җир участокларыннан башка) арендага бирү Тәртибен һәм Исемлеккә кертелгән муниципаль милекне формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибен раслау турында»гы 2017 елның 20 апрелендәге 83 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Әлеге карар белән расланган Теләче муниципаль районы милкендәге өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль милке (җир участокларыннан башка) Исемлеген формалаштыру,

алып бару һәм бастырып чыгару Тәртибенә (алга таба – формалаштыру Тәртибе) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) исемен түбәндәге тәртиптә бирергә:

«кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга файдалануга бирү өчен билгеләнгән Теләче муниципаль районы муниципаль милке Исемлеген формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастырып чыгару Тәртибе».

Б) Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга файдалануга бирү өчен билгеләнгән Теләче муниципаль районы муниципаль милке Исемлеген формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастырып чыгару Тәртибен 1нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бирергә.

2) Әлеге карар белән расланган муниципаль милек исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга файдалануга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль милкен (җир участокларыннан башка) арендага бирү Тәртибенә (алга таба - бирү Тәртибе) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

А) 3.2 пунктын түбәндәгечә бирергә:

«3.2. Аренда түләвенең башлангыч күләме бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән базар аренда түләвен бәяләү турындагы хисап нигезендә билгеләнә.»

Б) 3.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге тәртиптә бирергә:

«3.3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән исемлеккә кертелгән муниципаль милеккә карата аренда килешүен кимендә биш ел срокка төзегәндә, аренда хакы арендатор тарафыннан түбәндәге тәртиптә кертелә:»

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Теләче муниципаль районы Советының социаль-икътисадый мәсьәләләр буенча комитетына йөкләргә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы И.Ф.Зарипов

Теләче муниципаль
район Советының
2019 елның 14 нче июненнән
175 санлы карарына
1нче кушымта

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга файдалануга бирү өчен билгеләнгән Теләче муниципаль районы муниципаль милке Исемлеген формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастырып чыгару ТӘРТИБЕ

1. Гомуми нигезләмәләр.

Әлеге Тәртип кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга файдалануга бирү өчен билгеләнгән Теләче муниципаль районы муниципаль милке Исемлеген (алга таба – Исемлек) формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен, әлеге милекне озак сроклы нигездә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга (алга таба - ярдәм инфраструктурасы оешмалары) бирү максатларында, исемлеккә кертелүче милеккә таләпләрне билгели.

2. Исемлекне формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастырып чыгаруның максатлары һәм төп принциплары.

2.1. Исемлектә өченче затлар хокукыннан азат булган (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милеккә хокукларыннан тыш), «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында»гы 2007 елның 24 июлендәге 209 номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 өлешендә каралган, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез милекне алу үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2008 елның 22 июлендәге 159 номерлы Федераль закон нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләүсез нигездә читләштерү мөмкинлеге булган ярдәм инфраструктурасы оешмаларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка (шул исәптән аренда хакының ташламалы ставкалары буенча) файдалануга бирү өчен билгеләнгән Теләче муниципаль районының муниципаль милке турында һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очраклардагы белешмәләр тупланган.

2.2. Исемлек түбәндәге максатларда формалаша:

2.2.1. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм ярдәм инфраструктурасы оешмаларына Исемлеккә кертелгән милек турында мәгълүмат алу мөмкинлеген тудыру.

2.2.2. Теләче муниципаль районының милек хокукындагы милкен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, ярдәм инфраструктурасы оешмаларына озак вакытка (шул исәптән түләүле, түләүсез һәм аренда хакының ташламалы ставкалары буенча) файдалануга бирү өчен.

2.2.3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү өлкәсендә җирле үзидарә органы вәкаләтләрен тормышка ашыру.

2.2.4. Теләче муниципаль районы милкендә булган муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү, Теләче муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүне стимуллаштыру.

2.3. Исемлекне формалаштыру һәм алып бару түбәндәге төп принципларга нигезләнә:

2.3.1. Исемлеккә кертелә торган милек турындагы белешмәләрнең дөреслеге һәм Исемлеккә кертелгән милек турындагы мәгълүматның актуальлеген саклап калу.

2.3.2. Исемлекне ел саен агымдагы елның 1 ноябренә кадәр актуальләштерү.

2.3.3. Исемлекне формалаштыру һәм тулыландыру барышында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерцияле булмаган оешмелар, кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә үсеш институтлары белән хезмәттәшлек итү.

3. Исемлекне формалаштыру, алып бару, аңа үзгәрешләр кертү, шул исәптән ел саен Исемлеккә өстәмә кертү.

3.1. Исемлек, андагы үзгәрешләр, ел саен кертелә торган өстәмәләр Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән (алга таба - вәкаләтле орган) раслана. Вәкаләтле орган исемлектә булган мәгълүматларның дөреслеге өчен җавап бирә.

3.2. Исемлеккә милек турында түбәндәге критерийларга туры килә торган мәгълүматлар кертелә:

3.2.1. Милек өченче затлар хокукларыннан азат (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш);

3.2.2. Федераль законнар тарафыннан милеккә карата аны вакытлыча биләү һәм (яки) файдалануга, шул исәптән арендага бирүне тыю каралмаган;

3.2.3. Милек дини билгеләнештәге объект түгел;

3.2.4. Милек агымдагы елда һәм чираттагы чорга «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178 номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителгән муниципаль милекне хосусыйлаштыруны планлаштыру турындагы актка, шулай ук социаль юнәлештәге коммерцияле булмаган оешмаларга озак сроклы нигездә файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Теләче муниципаль районы милке исемлегенә кертелмәгән;

3.2.5. Милек авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип танылмаган;

3.2.6. Милек торак фондына яки торак фонды объекты тоташтырылган инженерлык-техник тәэмин итү челтәре объектларына керми;

3.2.7. Җир участогы шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнмәгән;

3.2.8. Җир участогы, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирелгән җир участокларыннан тыш, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктның 1-10, 13-15, 18 һәм 19 пунктчаларында каралган җир участокларына керми;

3.2.9. Муниципаль унитар предприятиеләргә, хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукына ия булган муниципаль учреждениеләргә (алга таба - балансга тотучы) беркетелгән милекне, балансга тотучының күрсәтелгән милекне Исемлеккә кертү турында тәкъдиме, шулай ук Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының тиешле милекне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләү һәм (яки) файдалану өчен бирү максатыннан, Исемлеккә кертү өчен алыш-биреш килешүенә язмача ризалыгы;

3.2.10. Милек куллану процессында үз натураль үзлекләрен югалтучы әйберләргә (кулланыла торган әйберләргә), азкыйммәтле күчемле милеккә, хезмәт итү срогы биш елдан ким булган милеккә керми яки аны Россия Федерациясе законнары нигезендә биш елга һәм аннан да күбрәк срокка арендага бирү рөхсәт ителми, шулай ук бүленми торган әйбернең бер өлеше дә булып тормый.

3.3. Мәгълүматлары Исемлеккә кертелгән милекне муниципаль милекне хосусыйлаштыруны планлаштыру турындагы акт проектына яки күрсәтелгән актка өстәмәләр проектына кертү тыела.

3.4. Милек турында мәгълүматлар Исемлеккә милек төрләре (күчемсез милек (шул исәптән Бердәм күчемсез милек комплексы), җир участоклары, күчемле милек) буенча кертелә.

3.5. Милек турындагы мәгълүматларны Исемлеккә (шул исәптән ел саен өстәмәне) кертү, шулай ук милек турындагы мәгълүматларны Исемлектән төшереп калдыру Теләче муниципаль районының хокукый акты белән аның инициативасы буенча гамәлгә ашырыла. Милек Исемлегеннән төшереп калдыруны күздә тотмаган үзгәрешләрне Исемлеккә кертү Теләче муниципаль районы муниципаль милек реестрына тиешле үзгәрешләр кертү датасыннан 10 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3.6. Әлеге Тәртипнең 3.6 пунктында күрсәтелгән затлардан кергән тәкъдимнәрне вәкаләтле орган тарафыннан карап тикшерү алар кергән көннән алып 30 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

3.6.1. Тиешле хокукый акт кабул итеп, милек турында тәкъдим ителгән мәгълүматларны Исемлеккә кертү турында;

3.6.2. Тиешле хокукый акт кабул итеп, милек турында тәкъдим ителгән мәгълүматларны Исемлектән төшереп калдыру турында;

3.6.3. Милек турындагы мәгълүматларны Исемлеккә кертү мөмкинлеге булмау турында дәлилләнгән җавапны тәкъдим иткән затка тәкъдимнәрне исәпкә алудан баш тарту турында.

3.7. Милекне Исемлеккә кертү турындагы тәкъдимне исәпкә алудан баш тарту турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

3.7.1. Милек әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килми.

3.7.2. Хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән милеккә карата бер яки берничә зат: баланс тотучы, Теләче муниципаль районы, баланс тотучы милке белән килешүләр төзергә вәкаләтле зат тарафыннан милекне Исемлеккә кертүгә ризалык юк.

3.7.3. Күчмә милекнең үзенә карата аренда килешүен төзергә мөмкинлек бирүче аерым билгеләре юк.

3.8. Вәкаләтле орган Теләче муниципаль районының муниципаль милке турындагы мәгълүматларны Исемлектән төшереп калдырырга хокуклы, әгәр күрсәтелгән милек турында белешмәләр Исемлеккә кертелгән көннән ике ел дәвамында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан яки ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалардан кермәсә:

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан милек белән идарә итү һәм (яки) файдалану хокукы күчүне күздә тоткан килешү төзү хокукына, шулай ук җир участогын арендалау килешүен төзү хокукына аукционда (конкурста) катнашуга бер генә гариза да юк;

- милек, җир участокларын да кертеп, бирү турында, шул исәптән «Көндәшлекне яклау турында»гы 2006 елның 26 июлендәге 135 номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Җир кодексында каралган очракларда аукцион (конкурс) үткәрмичә дә, бер тәкъдим (гариза) дә юк.

3.9. Теләче муниципаль районының муниципаль милке турында мәгълүматлар түбәндәге очракларда Исемлектән төшереп калдырыла:

3.9.1. Милеккә карата Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә аны Теләче муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен куллану турында Карар кабул ителгән. Милекне исемлектән төшереп калдыру турындагы карарда милектән файдалану юнәлеше һәм тиешле карар реквизитлары күрсәтелә;

3.9.2. Теләче муниципаль районының милек хокукы суд карары буенча яки законда билгеләнгән тәртиптә туктатылган;

3.9.3. Һәлакәт аркасында яки бетерелү нәтиҗәсендә милекнең юкка чыгуы.

3.9.4. Милекнең физик яки мораль тузуы, авария хәлендә булуы нәтиҗәсендә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, файдалану өчен яраксыз дип танылуы;

3.9.5. Милек арендатор тарафыннан «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез милекне алу үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2008 елның 22 июлендәге 159 номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда милеккә алынган.

3.10. Вәкаләтле орган характеристикалары буенча максатчан файдалану өчен яраксыз хәлгә килгән милекне, мондый милек кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына яки ярдәм инфраструктурасы оешмасына арендатор тарафыннан Теләче муниципаль районының норматив- хокукый актлары нигезендә аңа капиталь ремонт һәм (яки) реконструкция үткәрүне тәэмин итү шартларында бирелә торган очраклардан тыш, Исемлектән төшерә.

3.10. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 3.10 пунктында күрсәтелгән нигезнең, 3.10.5 пунктыннан тыш, барлыкка килүе турында мәгълүмат алганнан соң, өч эш көненнән дә соңга калмыйча, милекне исемлектән төшереп калдыру турында карар кабул итү нияте турында арендаторга хәбәр итә.

## 4. Исемлекне бастырып чыгару һәм аңа кертелгән милек турында мәгълүмат бирү

4.1. Вәкаләтле орган:

4.1.1. Исемлекне яисә Исемлектәге үзгәрешләрне расланган көннән соң 10 эш көне эчендә кушымта нигезендәге форма буенча массакүләм мәгълүмат чараларында бастыруны тәэмин итә;

4.1.2. Исемлекне вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Исемлекне яисә Исемлектәге үзгәрешләрне раслаган көннән соң 3 эш көне эчендә, 2нче кушымта нигезендәге форма буенча (шул исәптән ачык мәгълүматлар формасында) урнаштыруны гамәлгә ашыра.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга файдалануга бирү өчен билгеләнгән Теләче муниципаль районы муниципаль милке Исемлеген формалаштыру, алып бару, ел саен тулыландыру һәм бастырып чыгару Тәртибенә кушымта

Теләче муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына файдалануга бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек Исемлеге формасы

| № п/п | Объект-ның ад - ресы (урнаш-кан урыны) | Күчемсез объект төре, күчем-ле милек тибы | Хисап объекты исеме | Күчемсез милек турында мәгълүмат | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Күчемсез объектның төп характеристикасы | | |
| | | | | Тибы (мәйдан-җир участоклары, биналар, бүлмәләр өчен; озынлык, күләм, мәйдан, яту тирәнлеге-корылмалар өчен; проект документациясе буенча озынлык, күләм, мәйдан, яту тирәнлеге-тәмамланмаган төзелеш объектлары өчен | | Үлчәү берәмлеге (мәйдан өчен- кв.м, озынлык өчен – м, яту тирәнлеге өчен – м, күләм өчен- куб.м) |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

| Күчемсез милек турында мәгълүматлар | | | | Күчемле милек турында мәгълүматлар |
|---|---|---|---|---|
| Кадастр номеры | Күчемсез милек объектының техник | Җир-ләр ка-тегори-ясе | Рөхсәт ителгән куллану төре | |

| Но-мер | Тибы (кадастр, шартлы, искергән) | торышы | | | Дәүләт теркәве билгесе (булганда) | Марка, моделе | Чыгару елы | Милекнең составы (кирәк-яраклары) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |

| Хокукка ия булучылар һәм милеккә өченче затларның хокуклары турында мәгълүматлар | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Аренда һәм түләүсез файдалану килешүләре өчен | | Хокук иясенең исеме | Милек хокукы чикләнгән булу | Хокук иясенең ИНН | Контакт телефоны номеры | Электрон почта адресы |
| Милеккә аренда яки түләүсез файдалнуга хокук барлыгы | Килешү срогы тәмамлану датасы (булган очракта) | | | | | |
| 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 |